**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Коммерциячел булмаган оешманы гамәлгә куючы (оешмада катнашучы) вәкаләтләрен Татарстан Республикасы исеменнән гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы 1 өлешенең 3 пунктындагы «д» пунктчасы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның $12^1$ статьясындагы $3^4$ өлешенең 4 пункты нигезендә **карар бирәм:**

1. Гамәлгә куючысы (катнашучысы) Татарстан Республикасы булган коммерциячел булмаган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә түләүсез нигездә эш итүнең кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 14 март
№ 200

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2025 елның «14» мартындагы
200 номерлы Указы белән
расланды

**Гамәлгә куючысы (катнашучысы) Татарстан Республикасы булган коммерциячел булмаган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләреннән түләүсез нигездә эш итүнең тәртибе**

1. Әлеге Тәртиптә гамәлгә куючысы (катнашучысы) Татарстан Республикасы булган коммерциячел булмаган оешманың (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә түләүсез нигездә эш итү җайга салына.

2. Әлеге Тәртипнең гамәле гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциячел булмаган оешмаларның идарә органнарында Татарстан Республикасы вәкилләренең катнашуына бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

3. Коммерциячел булмаган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – Татарстан Республикасы вәкилләре) аларны коммерциячел булмаган оешманың идарә органы яисә ревизия комиссиясе составына кертү турында Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органы акты нигезендә Татарстан Республикасы мәнфәгатьләреннән эш алып бара.

4. Татарстан Республикасы вәкилләре түбәндәгеләрне эшләргә бурычлы:

коммерциячел булмаган оешманың идарә органы, ревизия комиссиясе эшендә түләүсез нигездә шәхсән катнашырга тиешләр һәм алар үз функцияләрен башка затларга тапшыра алмыйлар;

карарлар кабул иткәндә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Тәртипкә таянып, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, коммерциячел булмаган оешманы гамәлгә куючы (оешмада катнашучы) функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы республика башкарма хакимияте органы йөкләмәләренә таянып, Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен якларга.

5. Татарстан Республикасы вәкилләренең коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге турында алынган мәгълүматны шәхси мәнфәгатьләрендә, өченче затлар мәнфәгатьләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы

мәнфәгатьләренә каршы килә торган максатларда файдаланырга хокукы юк.

6. Татарстан Республикасы вәкиленең вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

Татарстан Республикасы вәкиленең Татарстан Республикасы вәкиле вәкаләтләрен башкарудан азат итү турында язма гаризасы булганда;

Татарстан Республикасы вәкиленең эш йөртергә юридик хокукы булмаганда, аның үлеме, шулай ук гражданны хәбәрсез югалган яки үлгән дип тану турында суд карары үз көченә кергәндә;

коммерциячел булмаган оешма үзгәртеп оештырылганда яки бетерелгәндә;

Татарстан Республикасы вәкиле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат булган очракта, ул Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан азат ителгәндә, Татарстан Республикасы вәкиле Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәре булган очракта, ул Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән чыгарылганда;

Татарстан Республикасына һәм (яки) коммерциячел булмаган оешмага зыян китергән гамәлләр кылынганда (гамәл кылынмаганда);

Татарстан Республикасы вәкиле җинаять җаваплылыгына тартылганда.

7. Татарстан Республикасы вәкиле вәкаләтләре Татарстан Республикасы вәкилен коммерциячел булмаган оешманың идарә органы яисә ревизия комиссиясе составыннан чыгару турында Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органы акты нигезендә туктатыла.

---